| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.072020 ел Баулы шәһәре №150

2020 елда Баулы муниципаль
районы сулыкларында кешеләрнең
иминлеген тәэмин итү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында” 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы “Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен раслау турында” карары нигезендә, Баулы муниципаль районы сулыкларында кешеләрнең куркынычсызлыгын һәм гомерен саклауны тәэмин итү максатларында Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләре»н (алга таба - Кагыйдәләр) үтәргә һәм аларга таянырга.

2. Баулы муниципаль районында су коену һәм массакүләм ял итү өчен махсус урын итеп Баулы шәһәренең ачык шәһәр бассейнын билгеләргә.

ТР буенча Роспотребнадзор идарәсенең Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Ютазы районнарындагы территориаль бүлеге белән килештереп, аны массакүләм ял итү һәм коену өчен файдаланырга.

3. Баулы шәһәре һәм Баулы муниципаль районы территориясендә халыкны махсус билгеләнмәгән урыннарда су коенуны тыярга.

4. Авыл җирлекләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- авыл җирлекләре территориясендә су коену һәм массакүләм ял итү өчен махсус урыннарны билгеләргә, Кагыйдәләрдә билгеләнгән таләпләр нигезендә пляжларны төзекләндерергә;

- махсус булмаган урыннарда коенуны тыярга.

5. «Баулы-ГорСервис» МКПын 2020 елның 30 июленә кадәр Россия Федерациясе Су кодексының 6нчы, 27нче маддәләре нигезендә Баулы шәһәренең ачык бассейнында Кагыйдәләрдә билгеләнгән таләпләр нигезендә пляж оештыруны тәкъдим итәргә.

6. Баулы муниципаль районының сулыкларда (буаларда, ачык бассейннарда һәм пляж зоналарында) иминлекне тикшерү комиссиясе (алга таба - комиссия) составын расларга (әлеге карарга кушымта).

7. Комиссия рәисенә Баулы муниципаль районының сулыкларда (буаларда, ачык бассейннарда һәм пляж зоналарында) иминлеген тикшерүне 2020 елның 30 июленә кадәр уздырырга.

8. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Баулы муниципаль районы буенча бүлеге начальнигына (килешү буенча) рөхсәт ителгән пляж зоналарында хокук тәртибен үтәүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

9. Баулы муниципаль районы Советының массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге җитәкчесенә (килешү буенча) суда куркынычсызлык кагыйдәләре турында кыска метражлы кинофильмнар күрсәтүне оештырырга, елга һәм сулыклар янында, шулай ук Баулы муниципаль районы территориясендәге су коену өчен җиһазланмаган, куркыныч һәм тыелган урыннарда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында халыкка даими рәвештә мәгълүмат бирергә тәкъдим итәргә.

10. “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге” МКУ җитәкчесенә шәһәр һәм район мәктәпләрендә укучылар һәм персонал өчен суда куркынычсызлык кагыйдәләрен өйрәнү буенча чаралар үткәрергә.

11. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының спорт һәм туризм үсеше бүлеге» МКУ башлыгына йөзү күнекмәләрен үзләштерү буенча күрсәтмә чаралар, җәйге чорда суда, шәһәр һәм район студентлары арасында экстремаль ситуациядә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре буенча күрсәтмә чаралар оештырырга.

12. "Баулы-ГорСервис" МКПны суда зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү өчен су коену сезонында кизү торуны оештырырга тәкъдим итәргә.

13. Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Ютазы районнарында территориаль бүлеге начальнигына (килешү буенча) Баулы муниципаль районы сулыкларында эпидемиологик хәлне тикшереп торуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

14. Халыкның күпләп ял итүе өчен билгеләнгән урыннарда 2020 елның су коену сезоны срогын Баулы муниципаль районында 2020 елның 30 июленнән 2020 елның 31 августына кадәр билгеләргә.

15. Баулы муниципаль районында су коену өчен ясалма сулыклары булган оешмалар җитәкчеләренә Кагыйдәләр нигезендә су объектларында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү чараларын оештырырга.

16. Әлеге карарны http://www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://www.bavly.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырырга.

17. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

18. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе — И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы Башкарма
комитетының 2020 елның 27
июлендәге 150 карарына
кушымта

Баулы муниципаль районының сулыкларда (буаларда, ачык бассейннарда һәм пляж зоналарында) иминлекне тикшерү комиссиясе (алга таба - комиссия) составы

Гозәеров И.И. - Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

житәкчесе, комиссия рәисе;;

| | | |
|---|---|---|
| Алексеев Г.В. | - | «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча); |
| Вәлиев И.Р. | - | Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары; |
| Ганиева Д.З. | - | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы; |
| Иванов А.Н. | - | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Баулы муниципаль районы буенча бүлеге начальнигы; |
| Михайлова А.А. | - | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ җитәкчесе; |
| Сәбитова А.З. | - | Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Ютазы районнарында территориаль бүлеге әйдәүче белгече (килешү буенча); |
| Хөснуллина И.И. | - | Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары. |

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының эшләр
белән идарә итүчесе Х.С. Мөгыйнов